**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Бикмураз авылында гражданнар җыены карары**

14.11.2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Бикмураз авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Бикмураз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Бикмураз авылында яр буе зоналарын, сулыкларны чистартуга, торак пункт территориясен төзекләндерүгә (Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлауга, балалар мәйданчыгы өчен материал сатып алуга, кышкы чорда юлларны кардан чистартуга, җәйге вакытта территорияне чабуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алуга, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Бикмураз авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы _________ Р.Н. Шәрәфетдинов

Халык җыены секретаре _________ А.И.Гәләветдинова